**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлегенең Кәүҗияк торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салым кертү турында

**2024 ел 30 март** **№2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге башлыгының №1 нче карары 20.03.2024 ел. «Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлегенең Кәүҗияк торак пунктында гражданнар Җыенының «Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлегенең Кәүҗияк торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»17.11.2023 ел, №1 карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында", 17.11.2023 №2 “Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлегенең Кәүҗияк торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында” Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлегенең Кәүҗияк торак пунктында гражданнар җыены Карар итте:

1. «Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлегенең Кәүҗияк торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 17.11.2023 №1, «Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлегенең Кәүҗияк торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 17.11.2023 №2 гражданнар җыены карарларына түбәндәге редакциядәге чаралар бәян итеп үзгәрешләр кертергә,:

1) торак пункт территориясен төзекләндерү (Кавзияково торак пункты территориясендә юл кырыенда үлән чабу);

2) һәйкәлләрне төзү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) түгел) һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (ТР, Сарман муниципаль районы, Кәүҗияк авылы, Совет урамы, 14в йорт адресы буенча Кәүҗияк торак пунктында һәйкәл ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу));

3) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгынга каршы җиһазлар сатып алу: янгынга каршы рюкзак, Кәүҗияк торак пунктында су алу өчен янгын колонкасы);

4) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Җәлил урамындагы Кәүҗияк тыкрыгындагы вак таш япмаларын ремонтлау (таш ташу), мәгълүмат щитларын һәм күрсәткечләрен, үзгәрешле мәгълүмат билгеләрен (чик буе күрсәткечләрен торгызу)».

2. Җыен нәтиҗәләрен Кәүҗияк авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http://sarmanovo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән 7 көн эчендә бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль районы
Кәүҗияк авыл җирлеге башлыгы Ф. Ә. Хөснетдинов